**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге
423079 Яңа Ибрай авылы
Совет урамы, 5 йорт тел. (факс)
884344- 4-27-27

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Совет Новоибрайкинского сельского
поселения Аксубаевского
муниципального района
423079 с.Новое Ибрайкино
улица Советская, д.5
тел. (факс) 884344-4-27-27

# КАРАР

№ 22 2021ел, 2 июнь

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 25 гыйнварындагы 87 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив-хокукый актларны законнарга туры китерү максатыннан Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 25 гыйнварындагы 87 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

2. 125 пунктның 13 абзацында пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләрен, Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында милекчеләр өчен карар кабул итү мөмкинлеге тулысынча юкка чыгарылырга тиеш түгел»;

184 пункчаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) алкоголь, наркотик яки токсик исерек хәлдә булган затлар, шулай ук яше яки сәламәтлеге торышы аркасында этләрнең хәрәкәтен контрольдә тота алмый торган һәм урамда йөргән вакытта аларның агрессив тәртибен булдырмый калган затлар этләрне урамда йөртү...»;

177 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«этне урамда йөртү, өч айга кадәрге эт балаларын һәм кечкенә этләрне йөртү (әгәр алар махсус сумкада (контейнерда) яки аларны урамда йөртүче зат кулында булмаса) очракларыннан тыш, муенчаклы бау (этне тотып торучы башка җайланмалар), муенчак һәм борынчыкны кулланып башкарылырга тиеш. Әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этнең муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелергә тиеш. Этне муенчаклы баусыз урамда йөртү торак пунктларның чикләреннән читтә, шулай ук этләрне урамда йөртү өчен билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә».

6 пунктның 64 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төзекләндерү элементлары - декоратив, техник, планировка, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлар һәм бизәү элементлары, шул

исәптән биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең фасадларының, кече архитектура формалары, капиталь булмаган стационар булмаган корылмалар һәм төзелмәләр, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган күрсәткечләр;»

6 пунктның 44 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«якын-тирә территория-мондый җир кишәрлеге барлыкка килгән һәм чикләре Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән очракта, бина, төзелмә, корылма, җир кишәрлеге янәшәсендәге гомуми файдаланудагы территория;»

6 пунктның 30 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«стационар булмаган сәүдә объекты - вакытлыча корылмадан яисә вакытлыча конструкциядән торган, инженерлык-техник тәэминаты челтәрләренә тоташтырылуга (технологик тоташтырылуга) карамастан, җир кишәрлеге белән нык бәйле булмаган сәүдә объекты, шул исәптән күчмә корылма;»

6 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«территорияне төзекләндерү - муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру, гражданнарның яшәү шартларын яхшырту, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшырту, мондый территорияләрдә урнашкан торак пунктларның территорияләрен, шул исәптән гомуми кулланылыштагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне, торак пунктларның территорияләрен, шул исәптән гомуми кулланылыштагы территорияләрне, биналарны,төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тоту буенча эшчәнлек;»

- 10 пунктта, 12 пунктның 2 пунктчасында, 36 пунктта, 64 пунктта, 73 пунктта, 86 пунктта:

«муниципаль заказ» сүзләрен «дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарны сатып алу, эш башкару, хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы: Ф.Х.Кабиров